**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ**
**ГОРОДА ЛАИШЕВО**

ул. Коммунальная, д.3,
г.Лаишево,422610

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ЛАЕШ ШӘҺӘРЕ**
**БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

Коммунальная ур., 3 нче йорт,
Лаеш ш.,422610

тел: 8-(84378) -2-57-77, факс: 8-(84378) -2-50-62, e-mail:Gorod.La@tatar.ru

**2024 елның 23 октябре** **14 номер**

# КАРАР

## «Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Лаеш шәһәре " муниципаль берәмлеге территориясендә җирләү эше мәсьәләләре буенча махсуслаштырылган хезмәт статусын бирү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы, «Җирләү һәм күмү эше турында» 1996 елның 12 гыйнварындагы 8-ФЗ номерлы Федераль законнар белән, «Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы территориясендә җирләү эше мәсьәләләре буенча махсуслаштырылган хезмәт вазыйфаларын башкару буенча түләүсез нигездә хезмәт күрсәтүче оешмаларны сайлап алу буенча конкурс уздыру тәртибе турындагы нигезләмәне раслау турында, конкурс комиссиясе төзү һәм конкурс комиссиясе турындагы нигезләмәне раслау хакында» Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Лаеш шәһәре башкарма комитетының 2024 елның 18 сентябрендәге 13 номерлы карары белән, 2024 елның 21 октябрендәге Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Лаеш шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә җирләү мәсьәләләре буенча махсуслаштырылган хезмәт функцияләрен башкару буенча түләүсез нигездә хезмәт күрсәтүче оешманы сайлап алу буенча конкурста катнашуга конвертларны ачу һәм гаризаларны карау, бәяләү һәм чагыштыру протоколы нигезендә:

1. Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы «Вечность» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең Лаеш шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә җирләү мәсьәләләре буенча махсуслаштырылган хезмәт статусын бирергә.
2. Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Лаеш шәһәре башкарма комитетына «Вечность» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте белән Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Лаеш шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә җирләү буенча хезмәтләр күрсәтү турында шартнамә төзергә.

3. Әлеге карарны Интернет телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru. веб–адресы буенча һәм интернет телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре Порталында урнаштырылган Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының рәсми сайтында-https://laishevo.tatarstan.ru/poleznaya-informatsiya-5827649.htm.веб-адресы буенча бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

Җитәкче В.А. Арефьев